ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының аерым Карарларын көчен югалткан дип тану турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль махсуслаштырылган фондның махсуслаштырылган торак урыннарын наймга бирү килешүләре буенча торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезнамәне раслау турында» 12/6 санлы Карарын «Челнинские известия» газетасының 2006 ел, 24 майдагы 93-94 нче саннарында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2007 елның 20 ноябрендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль махсуслаштырылган фондның махсуслаштырылган торак урыннарын наймга бирү килешүләре буенча торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезнамәне раслау турында» 12/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 27/16 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2007 ел, 07 декабрьдәге 233-235 нче саннарында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы 12/6 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль махсуслаштырылган фондның махсуслаштырылган торак урыннарын наймга бирү килешүләре буенча торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 25/9 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 11 июньдәге 44 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 11 июньдәге 44 нче санында бастырылган.

2.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев